РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск № 105

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында тегәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаган булса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 23 июнендәге 200 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында ачык хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаган булса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 23 июнендәге 200 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга кушымтада:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылыкның бер чарасын куллану мәсьәләсе Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы (алга таба - Совет) тарафыннан карала.

Әлеге мәсьәләне карау өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 73 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы нигез була.»;

б) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов